**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы.**
**КАРАР**

№ 61 27 август 2018 ел

«Ышаныч югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестры турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 05 мартындагы 228 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә вәкаләтле дәүләт органына (вәкаләтле оешмага) мәгълүмат җибәргән өчен җаваплы вазыйфаи затны билгеләү турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 25.12.2008 № 273-ФЗ Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 5 мартындагы 228 номерлы карары белән расланган ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестры турындагы нигезләмәне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге Советы
Карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестры турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә вәкаләтле дәүләт органына (вәкаләтле оешмага) мәгълүмат җибәрү өчен җаваплы зат итеп билгеләргә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестры турында» 2018 елның 05 мартындагы 228 номерлы карары белән расланган реестрга, ышанычны югалту сәбәпле эштән азат ителгән затлар реестрыннан чыгарулар.
2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары ышаныч югалту сәбәпле эштән азат ителгән очракта, аның турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан вәкаләтле дәүләт органына (вәкаләтле оешмага) тапшырыла.
3. Әлеге карарны мәгълүмат стендына элгән килеш игълан итәргә һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе: Г. Г. Дәүләтшин